| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БИМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2024 Бима авылы № 13

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге территориясендә гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча укыту-консультация пунктлары булдыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.02.2024 елның 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 48 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге территориясендә гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча укыту-консультация пунктлары булдыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.02.2024 елның 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының веб-адрес буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Э.И. Михайлов